Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXII-6**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 31 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 28.12.2017 ел, №XXV-6 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик рекомендацияләр турында” 2022 ел, 29 март, №под-583/22 боерыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 28.12.2017 ел, №XXV-6 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә (19.02.2018 ел, №XXIX-2 карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Нигезләмә) әлеге карарга бирелгән кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр кертергә.

2. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгына әлеге карар нигезендә Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче номерлы районара инспекциясендә билгеләнгән тәртиптә Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә вәкаләтләр бирергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгы И.М. Садиковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2022 елның
XXII-6 номерлы карарына

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 28.12.2017 ел, №XXV-6 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә (19.02.2018 ел, №XXIX-2 карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Бүлекнең структурасы

Бүлек структурасына керә:

- бүлек башлыгы (1);
- тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары (1);
- укыту-методик эш буенча башлык урынбасары – мәгълүмати-методик бүлек мөдире (1);
- мәгълүмати-методик бүлек (10);
- финанс-хуҗалык бүлеге (25).”.

2) 9.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9.3. Бүлек башлыгы, тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары, укыту-методик эш буенча башлык урынбасары – мәгълүмати-методик бүлек мөдире Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты органының вазыйфаи затлары (урындагы кешеләре) була. Бүлек башлыгы, тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары – муниципаль хезмәткәрләр.”;

3) 9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9.5. укыту-методик эш буенча башлык урынбасары – мәгълүмати-методик бүлек мөдире:”;

4) 9.5.8 пунктчасында “укыту-методик эш буенча бүлек методистлары” сүзтезмәсен “мәгълүмати-методик бүлек методистлары” сүзтезмәсе белән алмаштырырга;
5) 9.6.8 пунктчасында “Бүлек” сүзен төшереп калдырырга.